**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 04 апреле | 482 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы шәһәр яны урманчылыгы Матюшинск участок урманчылыгының 55 нче урман кварталына караган 2,16,18 нче урман таксация бүлендекләре өлешендә, 59 нчы урман кварталының 2-6,11,13,14,35 нче урман таксация бүлендекләре өлешендә электр тапшыру линиясе һәм җир асты үткәргече (газүткәргеч) линияле объект территориясен чикләү проектын әзерләү турында” 2023елның 21 декабрендәге 4006 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставы нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү һәм линия объектларын урнаштыру максатларында, карар бирәм:

1. “Татарстан Республикасы шәһәр яны урманчылыгының Матюшинск участок урманчылыгының 55 нче урман кварталының 2,16,18 нче Урман таксация бүлендекләре өлешендә, 59 нчы урман кварталының 2-6,11,13,14,35 нче урман таксация бүлендекләре өлешендә электр тапшыру линиясе һәм җир асты үткәргече (газүткәргеч) 2023елның 21 декабрендәге 4006 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарның исемен»Татарстан Республикасы шәһәр яны урманчылыгының Матюшинск участок урманчылыгының 55,59,93 урман кварталлары өлешендә электр тапшыру линиясе һәм җир асты үткәргече (газүткәргеч) " белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**